| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

15 май 2020 ел № 60/1

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Түбән Чәке авыл җирлегенең халык хокукларын тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-РТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Уставына таянып, муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу өчен, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге Советының 2014 елның 25 гыйнварындагы 37/1 номерлы карары («Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге жирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 10 апрелендәге 49/1 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге жирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны авыл жирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат такталарында: Түбән Чәке авылы, Советская урамы, 11 йорт МФЦ бинасы, Татар Шатрашаны авылы, Чкалова урамы, 20 йорт МФЦ бинасы.

Түбән Чәке авыл жирлеге башлыгы Албутов Олег Борис улы

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Түбән Чәке авыл
жирлеге Советының
2020 елның 15 маендагы
60/1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге жирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1. 26 статьяда:**

**8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«8. Төзелешкә рөхсәтләр алу өчен проект документациясенең составы, аны рәсмиләштерү тәртибе һәм тапшыру Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы һәм аның нигезендә башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 13 нче бүлегендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, капиталь төзелеш объектларының проект документациясе составына түбәндәге бүлекләр кертелә:

1) капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен башлангыч белешмәләр белән, шул исәптән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыруның) техник шартлары белән, һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен экспертиза уздырганда, проект документациясенә инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә уңай экспертизаның реквизитлары белән чыгыш язуны аңлатма язу;

2) жир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган жир кишәрлеген планлаштыру оештыру схемасы, ә проект документациясен линия объектларына карата әзерләнгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган билгеләнгән полоса проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документларын эшләү таләп ителмәгән очраклардан тыш);

3) архитектура, функциональ-технологик, конструктив һәм инженер-техник чишелешләр һәм (яисә) утәлүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар булган бүлекләр;

а) техник регламентлар таләпләре, шул исәптән механик, янгын һәм башка иминлек таләпләре, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре, биналар, корылмалар, энергетика ресурсларын биналарга, төзелешләргә һәм корылмаларга (шул исәптән алар составына керә торган челтәрләргә һәм инженер-техник тәэмин итү системаларына) карата исәпкә алу приборлары белән җиһазландыру таләпләре, капиталь төзелеш объектына инвалидларның керүен тәэмин итү таләпләре (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, административ, финанс, дини объектларга, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләгәндә);

б) санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен имин файдалануга таләпләр, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләре, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр, объектларның террорчылыкка каршы якланганлыгы таләпләре;

в) биналарны һәм корылмаларны проектлау, төзү, монтажлау, җайга салу, эксплуатацияләү процессларына таләпләр;

г) капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыруның) техник шартлары таләпләре;

4) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проекты;

5) капиталь төзелеш объектларын куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итүгә таләпләр;

6) капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау эшләрен башкаруның мондый объектны куркынычсыз эксплуатацияләнүен тәэмин итү өчен кирәкле, шулай ук күпфатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документациясен әзерләгән очракта күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы турында белешмәләр.

7) Проект документациясе бүлекләренең составына һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына тапшырыла торган эчтәлегенә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының (шул исәптән линия объектларына) төрле төрләренә карата, шулай ук капиталь төзелеш объектлары, эшләр төрләре (капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау), аларның эчтәлеге, эшләрне финанслау чыганаклары һәм әлеге статьяның таләпләре нигезендә төзелешнең, реконструкциянең аерым этапларын бүлеп бирү чыганаклары билгеләнүгә һәм түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып дифференциацияләнә:

а) проект документациясен әзерләү капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә карата аерым бүлекләр күләмендә (шул исәптән линия объектларына) гамәлгә ашырыла, шулай ук капиталь төзелеш объектларын

реконструкцияләгәндә башкарыла торган эшләр эчтәлегенә бәйле рәвештә (капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта) проектлаучы яисә техник заказчы биреме нигезендә;

б) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проектында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен җимерү эшләрен оештыру проекты булырга тиеш (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен капиталь төзелешнең башка объектларын төзү, реконструкцияләү өчен сүтү кирәк булган очракта);

в) проект документациясендә булган карарлар һәм чаралар мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш (мондый объектларның ышанычлылыгын һәм иминлеген конструктив һәм башка характеристикаларга кагыла торган мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен үткәрү өчен проект документациясен әзерләгән очракта);

г) проект документлары "Төзелешкә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, сүтүгә смета" бүлегеннән (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, әлеге Кодексның 8.3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән юридик затлар чараларын җәлеп итеп финансланган очракларда, капиталь ремонт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, әлеге Кодексның 8.3 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затлар акчаларын җәлеп итеп финанслана);

д) 1997 елның 21 июлендәге «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге турында» 116-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 пунктында, «Гидротехник корылмаларның иминлеге турында» 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясында, «Атом энергиясен файдалану турында» 1995 елның 21 ноябрендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында каралган очракларда, проект документлары составына мәҗбүри тәртиптә күрсәтелгән федераль законнарда каралган документация, документлар бүлекләре керә.